МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15. 12 2014 г. Казань № 7308/14

**Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премия бирү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 нче елның 7 нче июленнән һәм 2010 нчы елның 3 нче августыннан кабул ителгән «Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премия турында»гы 329 һәм 614 нче санлы карарлары нигезендә лаеклы булган педагогик коллективларга, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә ел саен Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премия бирелә.

Премия милли мәгарифне үстерүдә һәм Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятенең традицияләренә таянып, белем һәм тәрбия бирүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешкән, милли белем учреждениеләре өчен укыту-методик кулланмалар һәм фәнни хезмәтләр язган өчен билгеләнә.

2014 нче елда Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премиягә 11 эш кабул ителде. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 4 нче декабреннән 6912/14 нче боерыгы нигезендә тәкъдим ителгән кандидатураларның эшчәнлеге комиссия тарафыннан өйрәнелде һәм бәяләнде.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премияне билгеләү комиссиясе нәтиҗәләренә нигезләнеп, **БОЕРЫК БИРӘМ**:

1. 2014 нче елда Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премияләрне түбәндәге педагогик коллективка һәм аерым шәхескә бирергә:

- Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе коллективына;
- Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Имәнкискә урта гомуми белем мәктәбе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гаянова Кәүсәрия Гаяз кызына.

2. Лауреатларга «Ризаэддин Фәхреддин исемендәге бүләк» билгесен тапшырырга.

3. 2014 нче ел өчен Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премиягә тәкъдим ителгән хезмәткәрләрнең һәм коллективларның нәтиҗәле эшен билгеләп үтәргә, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломы белән бүләкләргә (1 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының исәп-

хисап бүлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 3 нче августыннан кабул ителгән «Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премия турында»гы 614 нче санлы карарына нигезләнеп, лауреатларга премия бирергә.

5. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр Э.Н. Фәттахов

Р.М. Фәхриева,
294–95–10

*1 нче кушымта*

2014 нче ел өчен Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премиягә тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге

| | |
|---|---|
| | **Коллективлар исемлеге** |
| 1. | Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясе коллективы |
| 2. | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе коллективы |
| 3. | «Рухият» рухи яңарыш фонды |
| 4. | Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе «Риза Фәхретдин исемендәге 1нче гимназия»се коллективы |
| 5. | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре «29 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе коллективы |
| | **Аерым шәхесләр исемлеге** |
| 6. | Татарстан Республикасы Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты доценты, филология фәннәре кандидаты Шаһиев Рәфкать Шириаздан улы |
| 7. | Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Дәвеш төп гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучысы Сабирова Лилия Сәгытдин кызы |
| 8. | Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль бюджет мэктэпкэчэ белем биру учреждениесе “Зоя бистэсе гомуми усеш бируче “Лэйсэн” балалар бакчасы” тәрбиячесе Шаһиева Алсу Расыйх кызы |
| 9. | «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Карауҗа гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Минһаҗева Әлфия Әсхәт кызы |
| 10. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы «Иске Рәҗәп урта гомуми белем биру мәктәбе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәйзиева Гөлназ Мөнир кызы |
| 11. | Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесеТатарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Имәнкискә урта гомуми белем мәктәбе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гаянова Кәүсәрия Гаяз кызы |